МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ
И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ
РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

№134-п 21.02.2022

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы каршындагы иҗтимагый шура турында нигезләмә раслау турында» 2021 елның 8 декабрендәге 1385-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы каршындагы иҗтимагый шура турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә иҗтимагый контроль нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый шура турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы каршындагы иҗтимагый шура турында нигезләмә раслау турында» 2021 елның 8 декабрендәге 1385-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы каршындагы иҗтимагый шура турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6.6 пунктның икенче кызыл юлына «әлеге пунктның беренче кызыл юлында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән биш көнлек чорда» сүзләрен өстәргә;

6.7 пунктның икенче кызыл юлына «әлеге пунктның беренче кызыл юлында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән биш көнлек чорда» сүзләрен өстәргә;

6.8 пунктның икенче кызыл юлына «әлеге пунктның беренче кызыл юлында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән биш көнлек чорда» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны министр урынбасары Е.А.Тарнавскийга йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков